РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ГЛАВА
Учаллинского сельского поселения
Азнакаевского муниципального
района

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

Азнакай муниципаль районы
Үчәлле авыл җирлеге
БАШЛЫГЫ

ул. Советская, д. 51 , село Учалле,
Азнакаевского муниципального района,
423317
Тел. (факс) (85592) 36-8-32
Uchal .Azn @tatar.ru

Совет урамы, 51, Үчәлле авылы
Азнакай муниципаль районы, 423317
Тел. (факс) (85592) 36-8-32
Uchal .Azn @tatar.ru

# ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

«20» октябрь 2020 ел. №4

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Үчәлле авыл җирлеге Якты Күл торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Азнакай муниципаль районы Үчәлле авыл җирлеге Уставы белән, карар чыгарам:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Үчәлле авыл җирлеге Якты Күл авылында теркәлгән һәм сайлау хокукына ия гражданнар өчен 2020 елның 31 октябрендә 10 сәгать 00 минутка үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләргә;

2.Билгеләргә:

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Үчәлле авыл җирлеге Якты Күл торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы – Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Үчәлле авыл җирлеге Башкарма комитеты;

- гражданнар Җыенын уздыру вакыты-2020 елның 31 октябрендә 10.00 сәгатьтән 11.00 сәгатькә кадәр;

- Халык җыенын үткәрү урыны- Якты Күл авылы, Якты Күл урамы, 15 нче йорт, Якты Күл авылындагы күпфункцияле үзәк;

3. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Үчәлле авыл җирлеге Башкарма комитетына тәкъдим итәргә:

- 2020 елның 19 октябреннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Үчәлле авыл җирлеге Башкарма комитетында гражданнар җыены карарына чыгарыла торган материаллар белән танышу хокукын гражданнарга түбәндәге адрес буенча бирергә: Үчәлле авылы, Совет урамы, 51 йорт; Якты Күл авылы, Якты- күл урамы,15 йорт.

- сайлау хокукына ия булган Якты Күл торак пунктында яшәүчеләр исемлеген төзергә;

- гражданнар җыенына мәгълүмати материаллар әзерләү;

-Якты Күл торак пункты халкына массакүләм мәгълүмат чараларында һәм гражданнарның җыены турында башка ысуллар белән хәбәр итәргә.

4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2021 Үчәлле авыл җирлеге Якты Күл торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, 1 төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, 500 сум күләмендә, 2 төркем инвалидлардан, түләүне киметеп, аны 250 сум күләмендә билгеләп, үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- бәйрәм чараларын оештыру һәм үткәрү («Яңа ел», «Җиңү көне», «Сабантуй», «Халыкара өлкәннәр көне», «Учук» бәйрәмнәрен үткәрүгә бүләк һәм сувенир продукциясен сатып алу);

- Якты- Күл авылында җирлекне яктырту һәм урамнарны яктырту буенча хезмәт күрсәтү (лампалар, яктырткычлар, электр товарлары һәм махсус җайланмалар сатып алу һәм алыштыру);

- Якты - Күл авылында җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын карап тоту: (Якты-Күл урамы буенча юлларга вак таш җәю (сатып алу һәм/яки ташу, вак таш җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү);

- Җирлек территорияләрен төзекләндерүне оештыру (Якты- Күл авылында балалар өчен уен мәйданчыгы сатып алу һәм урнаштыру, юлларны кардан чистарту буенча чит оешмалар хезмәтләре);

- Якты -Күл авылы зиратында контейнер мәйданчыкларын төзү (контейнер, киртә өчен материаллар сатып алу, коймалар әзерләү һәм урнаштыру, контейнер мәйданчыклары төзү (нигез, коймаларны урнаштыру);

- Җирлек территориясеннән каты коммуналь калдыкларны чыгару.

ӘЙЕ КАРШЫ».

5. Әлеге карарны Россия, Татарстан Республикасы, Азнакай районы, Үчәлле авылы, Совет урамы, 51 нче йорт; Россия, Татарстан Республикасы, Азнакай районы, Якты Күл авылы, Якты Күл урамы, 15 нче йорт адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә;

-Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru,

-Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru.

6. Әлеге карар ул халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Башлык Г.М.Төхвәтуллина